**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00
e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ**
**№ 3-2**

**КАРАР**
**от «12» октябрь 2020 ел**

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәрендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында»гы Нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында http://madysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый http://mamadysh.tatarstan.ru/веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советы рәисе — А.П.Иванов